**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 21 октябрендәге 4446 номерлы карары**

**2025 елга Казан шәһәренең балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениеләрен һәм балаларга өстәмә белем бирә торган күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын раслау турында**

2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы федераль законның 99 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законның 16 статьясындагы 1 пунктның 13 пунктчасы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы «Татарстан Республикасының балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениеләрен һәм балаларга өстәмә белем бирә торган күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау турында»гы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисади һәм социаль тикшеренүләр үзәге тарафыннан 2025 елга башкарылган исәпләүләргә таянып **карар бирәм**:

1. Түбәндәгеләрне расларга һәм 2025 елда гамәлгә кертергә:

1.1. 2025 елга Казан шәһәренең балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениеләре һәм балаларга өстәмә белем бирә торган

күппрофильле мәгариф учреждениеләре тарафыннан балаларга өстәмә белем бирү буенча күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күләмен (әлеге карарга 1 номерлы кушымта);

1.2. 2025 елга Казан шәһәренең балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениеләрендә һәм балаларга өстәмә белем бирә торган күппрофильле мәгариф учреждениеләрендә өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативларын (әлеге карарга 2 номерлы кушымта);

1.3. Казан шәһәренең балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениеләрендә балаларга өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәтләрне гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативларына 0,75 күләмендә төзәтмә коэффициентны;

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (И.А.Ризванов):

2.1. түбәндәгеләрне исәпкә алып, җыелма бюджет язмасын расларга:

- әлеге карарның 1.2-1.3 пунктчаларында күрсәтелгән финанслау нормативлары нигезендә, шулай ук хезмәт күрсәтү сыйфаты стандартлары нигезендә учреждениеләрнең өзлексез эшләвен тәэмин итү максатыннан ел саен кабул ителә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүгә чыгымнарның нормативтан артык күләмен исәпкә алып, балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениеләре тарафыннан муниципаль йөкләмәләрне үтәүгә субсидияләрне;

- 2025 ел дәвамында учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт хакы арту белән бәйле чыгымнарны түләүгә һәм учреждениеләрнең субсидия күләменә кермәгән башка чыгым йөкләмәләрен үтәүгә юнәлтү өчен бюджет акчаларының үзәкләштерелгән нормативтан артык күләмен;

2.2. ведомство карамагындагы балаларга өстәмә белем бирә торган муниципаль мәгариф учреждениеләренә субсидияләр бирүне муниципаль йөкләмәләрне үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә каралган бюджет акчалары хисабына субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы килешүләр нигезендә башкарырга;

2.3. 2025 елда балаларга өстәмә белем бирә торган учреждениеләргә укучылар контингенты үзгәрү өлешендә муниципаль йөкләмәләр үзгәргән очракта, Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә Казан шәһәренең җыелма бюджет язмасы чикләрендә чыгымнарны яңадан бүлү турында нигезләнгән тәкъдимнәр бирүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 21 октябрендәге
4446 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**2025 елга Казан шәһәренең балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениеләре һәм балаларга өстәмә белем бирә торган күппрофильле мәгариф учреждениеләре тарафыннан балаларга өстәмә белем бирү буенча күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күләме**

| № т/б | Балаларга өстәмә белем бирә торган күппрофильле мәгариф учреждениесе атамасы | Балаларга өстәмә белем бирә торган күппрофильле мәгариф учреждениесендә укучылар саны |
|---|---|---|
| 1 | Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | 3333 |
| 2 | Казан шәһәре Вахитов районының «Балалар иҗаты үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | 1700 |
| 3 | Казан шәһәре Вахитов районының «“Факел” балалар техник иҗаты үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | 737 |
| 4 | Казан шәһәренең «А.Алиш исемендәге шәһәр балалар иҗаты сарае» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | 4554 |

| № т/б | Балаларга өстәмә белем бирә торган күппрофильле мәгариф учреждениесе атамасы | Балаларга өстәмә белем бирә торган күппрофильле мәгариф учреждениесендә укучылар саны |
|---|---|---|
| 5 | Казан шәһәренең «Сәләтле балалар өчен иҗади үсеш һәм гуманитар белем бирү шәһәр үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | 230 |
| 6 | Казан шәһәренең «Күпмилләтле якшәмбе мәктәбе» мәгариф үзәге муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | 560 |
| 7 | Казан шәһәре Киров районының «“Заречье” балаларга өстәмә белем бирү үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 3727 |
| 8 | Казан шәһәре Киров районының «“Сәяхәт” балаларга өстәмә белем бирү үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 2255 |
| 9 | Казан шәһәре Мәскәү районының «Балалар һәм яшүсмерләр туризмы һәм экскурсияләр йорты» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | 1309 |
| 10 | Казан шәһәренең «В.П.Чкалов исемендәге балалар техник иҗаты шәһәр үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | 1290 |
| 11 | Казан шәһәре Мәскәү районының «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | 1390 |
| 12 | Казан шәһәре Яңа Савин районының «Балалар иҗаты үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | 3465 |
| 13 | Казан шәһәре Яңа Савин районының «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | 3118 |

| № т/б | Балаларга өстәмә белем бирә торган күппрофильле мәгариф учреждениесе атамасы | Балаларга өстәмә белем бирә торган күппрофильле мәгариф учреждениесендә укучылар саны |
|---|---|---|
| 14 | Казан шәһәре Яңа Савин районының «“Простор” балалар һәм яшүсмерләр туризмы һәм экскурсияләр йорты» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | 1220 |
| 15 | Казан шәһәре Идел буе районының «“Олимп” балалар иҗаты үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 3243 |
| 16 | Казан шәһәре Идел буе районының «Молодость» балалар (яшүсмерләр) үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | 1440 |
| 17 | Казан шәһәре Идел буе районының «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 4830 |
| 18 | Казан шәһәре Совет районының «Балалар һәм яшүсмерләр туризмы һәм экскурсияләр станциясе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 960 |
| 19 | Казан шәһәре Совет районының «“Азино” балалар иҗат үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 4579 |
| 20 | Казан шәһәре Совет районының «“Балалар академиясе” балалар иҗаты үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 2458 |
| 21 | Казан шәһәре Совет районының «“Танкодром” балалар иҗаты үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 3338 |
| 22 | Казан шәһәренең «Балалар экология-биология шәһәр үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 1672 |

| № т/б | Балаларга өстәмә белем бирә торган күппрофильле мәгариф учреждениесе атамасы | Балаларга өстәмә белем бирә торган күппрофильле мәгариф учреждениесендә укучылар саны |
|---|---|---|
| 23 | Казан шәһәре Совет районының «Дербышки поселогы балалар иҗаты үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 2935 |
| **БАРЛЫГЫ** | | **54 343** |

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 21 октябрендәге
4446 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**2025 елга Казан шәһәренең балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениеләрендә һәм балаларга өстәмә белем бирә торган күппрофильле мәгариф учреждениеләрендә өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар**

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Норматив чыгымнар (бер укучыга бер елга сумнарда) | | |
|---|---|---|---|
| | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | 8 280 | 15 333 | 18 399 |
| Физкультура-спорт | 8 179 | 15 145 | 18 174 |
| Техник иҗат | 8 583 | 15 895 | 19 074 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | 8 381 | 15 520 | 18 624 |
| Экология-биология | 8 381 | 15 520 | 18 624 |
| Хәрби-патриотик | 8 381 | 15 520 | 18 624 |
| Социаль-педагогик | 7 976 | 14 771 | 17 725 |
| Социаль-икътисади | 7 976 | 14 771 | 17 725 |
| Табигый-фәнни | 8 381 | 15 520 | 18 624 |

___